| Республика Татарстан | | Татарстан Республикасы |
|---|---|---|
| СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

13 март 2023 ел № 13

“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 19.12.2022 елгы №30 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты турында»гы карар буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставы турында» 2021 елның 17 декабрендәге 31 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга : https://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка хәбәр итәргә:

-Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы бистәсе, Школьная урамы, 31А йорт;

- Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы бистәсе, З.Йосыпов урамы;

- Татарстан Республикасы, Саба районы, Урта Саба авылы, Г.Тукай урамы, 33 йорт.

3. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставын дәүләт теркәве өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе юстиция Министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге башлыгы Р.М. Хәсәновка йөкләргә.

Саба шәһәр җирлеге башлыгы Р.М. Хәсәнов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 2023 елның 13 мартында кабул ителгән №13 карары белән
РАСЛАРГА

“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. 5 нче маддәнең 1 нче пунктында 40 нчы пунктчасында “ясалма җир участогы булдыру турында килешү төзү хокукына ачык аукцион үткәрү” сүзен алып ташларга;

2. 11 маддәнең 7 пунктының икенче абзацында «җирлекнең сайлау комиссиясе» дигән сүзләрне «җирле референдумга әзерлек һәм аны үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе (алга таба – сайлау комиссиясе)»дигән сүзләр белән алыштырырга;

3. 12 маддәнең 3 пунктының икенче абзацында «җирлекнең сайлау комиссиясе» дигән сүзләрне «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе (алга таба – сайлау комиссиясе)»дигән сүзләр белән алыштырырга;

4. 13 маддәнең 5 пунктында «җирлекнең сайлау комиссиясе» дигән сүзләрне «җирле референдумга әзерлек һәм аны үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе (алга таба – сайлау комиссиясе)»дигән сүзләр белән алыштырырга;

5. 13 маддәнең 8 пунктында "сайлау комиссиясе”сүзләреннән соң "торак пункт" сүзен алып ташларга;

6. 13 маддәнең 12 пунктында «сайлау комиссиясе» сүзләреннән соң «торак пункт» сүзен алып ташларга;

7. 19 нчы маддәнең 2 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Торак пункт старостасы аның составына керүче авыл җирлеге гражданнары җыены тәкъдиме буенча җирлек Советы тарафыннан билгеләнә. Староста әлеге авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары яки гражданнар җыены тәкъдим иткән көнне 18 яшькә җиткән һәм әлеге авыл җирлеге территориясендә урнашкан торак бинасы булган Россия Федерациясе гражданнары арасыннан билгеләнә.»;

8. 19 маддәнең 3 пунктының беренче абзацын «муниципаль вазыйфаны» дигән сүзләрдән соң “муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш, үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыра” дигән сүзләр белән тулыландырырга;

9. 19 маддәнең 4 пунктының 1 пунктчасын «муниципаль вазыйфаны» дигән сүзләрдән соң “муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш, үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыра” дигән сүзләр белән тулыландырырга;

10. 20 нче маддәнең 5 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Ачык тыңлаулар яки җәмәгать фикер алышулары үткәрү турында мәгълүмат, аларны үткәрү вакыты һәм урыны күрсәтелгән, шулай ук ачык тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты, җәмәгать тыңлаулары яки җәмәгать фикер алышулары уздырыла торган көнгә кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча, махсус мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш: https://saby.tatarstan.ru/saba, шулай ук «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы»федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру”;

11. 20 нче маддәнең 6 нчы пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Ачык тыңлаулар һәм муниципаль норматив хокукый акт проекты турында мәгълүмат бастырылган көннән башлап, җирлек халкы җирлек башлыгына ачык тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт мәсьәләсе яки проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шул исәптән «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша җибәрергә хокуклы.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр юнәлеше җәмәгать тыңлаулары уздырылганчы 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Җирлек башлыгы килгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерүне һәм аларны җәмәгать тыңлауларында катнашучыларга җиткерүне оештыра.»;

12. 20 нче маддәнең 9 нчы пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре торак пунктлар территориясендәге махсус мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырылырга тиеш: https://saby.tatarstan.ru/saba һәм «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында җәмәгать тыңлаулары яки җәмәгать тыңлаулары уздырылганнан соң 5 календарь көннән дә соңга калмыйча.».

13. 20 нче маддәнең 10 нчы пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Җәмәгать тыңлауларын һәм җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

14. 31 маддәнең 10 пунктында "Президент" сүзен “Башлык (Рәис)" сүзе белән алыштырырга;

15. 31 маддәнең 11 пунктында "Президент" сүзен “Башлык (Рәис)" сүзе белән алыштырырга;

16. 31 маддәнең 15 пунктында "Президент" сүзен “Башлык (Рәис)" сүзе белән алыштырырга;

17. 31 маддәнең 12 пункты үз көчен югалткан дип танырга;

18. 33 статьясының 1 пунктында «сайлау комиссиясе» сүзләреннән соң «торак пункт» сүзен алып ташларга;

19. 34 маддәнең 13 пунктында 1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

20. 41 нче маддәне түбәндәге эчтәлектәге 6 нчы пункт белән тулыландырырга:

«6. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатының вәкаләтләре муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән, әгәр депутат җитди сәбәпләрсез муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы утырышларында алты ай рәттән булмаса, вакытыннан алда туктатыла.»;

21. 41 маддәнең 5 пунктында "Президент" сүзен "Рәис" сүзе белән алыштырырга;

22. 43 маддәнең 1 пунктының икенче абзацында "Президент" сүзен “Башлык (Рәис)" сүзе белән алыштырырга;

23. 47 маддәнең 3 пунктының икенче абзацында "Президент" сүзен “Башлык (Рәис)" сүзе белән алыштырырга;

24. 47 маддәнең 4 пунктында "Президент" сүзен “Башлык (Рәис)" сүзе белән алыштырырга;

25. 50 нче маддәнең 12 нче пунктның 1 нче пунктчасында икенче абзацында “ясалма җир участогы булдыру турында килешү төзү хокукына ачык аукцион үткәрү” сүзен алып ташларга;

26. VII бүлек һәм 59 маддә үз көчен югалткан дип танырга;

27. 64 маддәнең 3 пунктында «сайлау комиссиясе» сүзләреннән соң «торак пункт» сүзен алып ташларга;

28. 87 маддәнең7 пунктының өченче абзацында «Президент» сүзен «башлык (Рәис)» сүзе белән алыштырырга.